РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Совет
Борискинского сельского поселения Алькеевского муниципального района

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Әлки муниципаль районы
Борис авыл җирлеге
Советы

422883, РТ, Алькеевский район, с. Борискино, Дружбы, 8
тел: : 8 (84346) 76-239

Адресы: 422883, РТ, Әлки районы, Борис авылы, Дуслык ур., 8
факс: 8 (84346) 76-239

**РЕШЕНИЕ** Борис авылы **КАРАР**

2022 елның 4 феврале 36№

**Әлки муниципаль районы Борис авыл җирлеге Советының 2021 елның 1 декабрендәге «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы «Борис авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турындагы нигезләмәне раслау хакында» 31 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 1 өлешенең 19 пункты, 2020 елның 31 июлендәге «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 248-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы «Борис авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Борис авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы «Борис авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Әлеге декарарга кушымта нигезендә Нигезләмәне 6 бүлек белән тулыландырырга.

Әлеге карарга кушымта нигезендә Нигезләмәне 3 нче кушымта белән тулыландырырга.

2.Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы «Борис авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында нигезләмәнең 6 бүлеге 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы «Борис авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турындагы нигезләмәнең 3 нче кушымтасындагы 2 пункт 18, 20 пунктчасы 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми http:pravo.tatarstan.ru порталында бастырып чыгарырга һәм Әлки

муниципаль районының рәсми http:arsk.tatarstan.ru сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

5.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Борис
авыл җирлеге башлыгы: Г.В.Самарина

Әлки муниципаль районы Борис авыл
җирлеге Советының 2022 елның 4 февралендәге
36 номерлы карарына кушымта

## 6. Судка кадәр шикаять

6.1. Муниципаль контрольне гамәлгә ашыру кысаларында хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре турыдан-туры бозылган санаган контрольдә торучы затлар Контроль органы җитәкчесе урынбасары һәм инспекторларның түбәндәге карарларына судка кадәр шикаять бирергә хокуклы (алга таба шулай ук - вазыйфаи затлар):

1) контроль чаралар уздыру турында карарлар;

2) контроль чаралар актлары, ачыкланган хокук бозуларны бетерү турында күрсәтмәләр;

3) контроль чаралар кысаларында вазыйфаи затларның гамәлләре (гамәл кылмаулары).

6.2. Шикаять контрольдә торучы зат тарафыннан Контроль органга Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталын һәм (яисә) Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең төбәк порталларын кулланып электрон рәвештә тапшырыла.

Шикаять биргәндә граждан тарафыннан гади электрон имза яки көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланырга тиеш. Оешма тарафыннан шикаять бирелгәндә, ул көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланырга тиеш.

Контрольдә торучы торган зат тарафыннан шикаятькә кушып бирелә торган материаллар, шул исәптән фото- һәм видеоматериаллар электрон рәвештә бирелә.

Дәүләт яисә закон белән саклана торган башка серне тәшкил итүче белешмә һәм документларны үз эченә алган шикаять, контрольдә торучы торган зат тарафыннан дәүләт яисә башка саклануча сер турында Россия Федерациясе законнары таләпләрен үтәп, дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең бердәм порталыннан файдаланмыйча, кәгазь чыганакта бирелә.

6.3. Контроль орган карарына, аның вазыйфаи затларының гамәле (гамәл кылмавы) карата бирелгән шикаять Контроль орган җитәкчесе тарафыннан карала.

Контроль органы җитәкчесенең гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять Әлки муниципаль районы авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан карала.

6.4. Шикаятьне контрольдә торучы зат үз хокукларын бозу турында белгән яки белергә тиеш булган көннән алып утыз календарь көн эчендә бирергә мөмкин.

Контроль орган күрсәтмәсенә шикаять контрольдә торучы зат күрсәтмә алган вакыттан алып ун эш көне эчендә бирелергә мөмкин.

6.5. Шикаять бирү срогын җитди сәбәп аркасында уздырган очракта, шикаять биргән контрольдә торучы затның үтенечнамәсе буенча әлеге срок Контроль орган тарафыннан торгызылырга мөмкин.

6.6. Шикаять биргән контрольдә торучы зат шикаять буенча карар кабул ителгәнче аны кире алырга мөмкин. Шул ук вакытта бер үк нигезләр буенча кабат шикаять бирү рөхсәт ителми.

6.7. Шикаятьтә Контроль органының дәгъвалана торган карарын үтәүне туктатып тору турындагы үтенеч булырга мөмкин.

6.8. Контроль орган җитәкчесе тарафыннан шикаятьне теркәгән көннән соң ике эш көненнән дә соңга калмыйча карар кабул ителә:

1) Контроль органның дәгъвалана торган карарын үтәүне туктатып тору турында;

2) Контроль органның дәгъвалана торган карарын үтәүне туктатып торудан баш тарту турында.

Кабул ителгән карар турында мәгълүмат шикаять биргән контрольдә торучы затка карар кабул ителгән вакыттан алып бер эш көне эчендә җибәрелә.

6.9. Шикаятьтә түбәндәге мәгълүматлар булырга тиеш:

1) карар һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерелә Контроль орган исеме, вазыйфаи затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта);

2) гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), яшәү урыны (эшчәнлеген гамәлгә ашыру урыны) турында белешмәләр, яки контрольдә торучы зат булган оешманың исеме, әлеге оешма урнашкан урын турында белешмәләр, яки ышанычнамә буенча шикаять бирүче затның ышанычнамәсе, фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда) реквизитлары, шикаятьне карау вакытына үзара эшчәнлекне башкаруның һәм аның буенча карар алуның теләгән ысулы;

3) Контроль орган һәм (яисә) аның вазыйфаи затының шикаять биргән контрольдә торучы затның хокукларын бозуга китергән яисә китерергә мөмкин карары турында белешмәләр;

4)Контрольдә торучы затның  Контроль орган карары һәм (яисә) вазыйфаи затның гамәле (гамәл кылмавы) ризалашмау нигезләре һәм дәлилләре. Контрольдә торучы зат тарафыннан аның дәлилләрен раслый торган документлар (булган очракта) яисә аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин;

5) шикаять биргән контрольдә торучы зат таләпләре;

6) Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан башкасы билгеләнмәгән булса, контроль (күзәтчелек) чараларының бердәм реестрында шикаять бирелгән контроль чараның исәпкә алу номеры.

6.10. Шикаятьтә Контроль органы вазыйфаи затларының яисә аларның гаилә әгъзаларының тормышына, сәламәтлегенә һәм мөлкәтенә карата цензурасыз яисә мыскыллаган әйтелмәләр, янаулар булырга тиеш түгел.

6.11. Тиешле хокук бирелгән очракта, шикаять бирү «Бердәм идентификация һәм аутентификация системасы» Федераль дәүләт мәгълүмат системасы ярдәмендә контрольдә торучы затның вәкаләтле вәкиле тарафыннан гамәлгә ашырылырга мөмкин.

6.12. Контроль орган шикаятьне караудан баш тарту турында биш көн эчендә карар кабул итә, әгәр:

1) шикаять әлеге Нигезләмәнең 6.4 пунктында билгеләнгән шикаять бирү сроклары тәмамланганнан соң бирелгән һәм шикаять бирүгә җибәрелгән срокны торгызу турында үтенечнамәне үз эченә алмый;

2) шикаять бирүгә җибәрелгән вакытны торгызу турындагы үтенечнамәне канәгатьләндерүдән баш тарту;

3)шикаять биргән контрольдә торучы заттан карар кабул ителгәнчегә кадәр шикаятьне кире алу турында гариза керү;

4) шикаятьтә куелган мәсьәләләр буенча суд карары булу;

5) элекрәк Контроль органга шул ук контрольдә торучы заттан шушы нигезләрдә башка шикаять бирелү;

6) шикаятьтә Контроль орган вазыйфаи затларының, шулай ук аларның гаилә әгъзаларының тормышына, сәламәтлегенә һәм мөлкәтенә цензурасыз яисә мыскыллы аңлатмалар, янаулар булу;

7) элек әлеге контрольдә торучы затның шул ук предмет буенча шикаять белән кабат мөрәҗәгать итү мөмкинлеген юкка чыгара торган караудан баш тарту булса һәм яңа дәлилләр яисә хәлләр китерелмәсә;

8) шикаятьнең тиешле булмаган органга бирелүе;

9) Россия Федерациясе законнарында Контроль орган карарларына шикаять белдерү буенча суд тәртибе генә каралу.

6.13. Әлеге Нигезләмәнең 5.12 пунктының 3-8 бүлекләрендә күрсәтелгән нигезләр буенча шикаятьне караудан баш тарту судка кадәр шикаять бирү нәтиҗәсе булып тормый һәм Контроль орган карарларына, вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата суд тарафыннан шикаять белдерү өчен нигез була алмый.

6.14. Шикаятьне караганда Контроль орган контроль эшчәнлеккә судка кадәр шикаять белдерү буенча Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган өстәмә системаны алып бару кагыйдәләре нигезендә контроль эшчәнлеккә судка кадәр шикаять бирү системасыннан файдалана.

Контроль орган судка кадәр шикаять бирү системасына шикаятьне карау барышы турында белешмәләр тапшыруны тәэмин итә.

Дәүләт яисә закон белән саклана торган башка серне тәшкил итүче белешмә һәм документларны үз эченә алган шикаять, контрольдә торучы торган зат тарафыннан дәүләт яисә башка саклanучы сер турында Россия Федерациясе законнары таләпләрен үтәп, дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең бердәм порталыннан файдаланмыйча, Контроль орган җитәкчесе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

6.15. Шикаять Контроль орган җитәкчесе тарафыннан теркәлгән көненнән алып егерме эш көне эчендә каралырга тиеш.

6.16. Күрсәтелгән срок аерым очракларда егерме эш көненә озайтылырга мөмкин:

1) шикаятьтә күрсәтелгән фактлар буенча шикаять бирелә торган вазыйфаи затның гамәл (гамәл кылмау)хезмәт тикшерүе үткәрү;

2) гамәлләренә (гамәл кылмавына) дәгъвалана торган вазыйфаи затның нигезле сәбәпле (авыру, отпуск, командировка) булмавы.

6.17. Контроль орган шикаять биргән контрольдә торучы заттан шикаять предметына кагылышлы өстәмә мәгълүмат һәм документлар соратырга хокуклы. Контрольдә торучы зат мөрәҗәгать җибәрелгән

вакыттан алып биш эш көне эчендә күрсәтелгән мәгълүмат һәм документларны тапшырырга хокуклы.

Шикаятьне карау срогы темасы өстәмә мәгълүмат бирү турында мөрәҗәгать һәм шикаять предметына караган документлар җибәрелгәннән алып аларны вәкаләтле орган алган мизгелгә кадәр, әмма мөрәҗәгать җибәрелгән вакыттан алып биш эш көненә кадәр туктатып торыла.

Контрольдә торучы заттан өстәмә мәгълүмат һәм шикаять предметына караган документларны алмау шикаятьне караудан баш тарту өчен нигез булып тормый.

6.18. Шикаятьне биргән контрольдә торучы заттан дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары яки аларга буйсынучы оешмалар карамагында булган мәгълүмат һәм документларны соратып алу рөхсәт ителми.

Шикаять биргән зат шикаять буенча йомгаклау карары кабул ителгәнчегә кадәр үз теләге белән шикаять предметына караган өстәмә материалларны тәкъдим итәргә хокуклы.

6.19. Кабул ителгән карарның законлылыгын һәм (яисә) башкарылган гамәлләрнең (гамәл кылмауның) нигезлелеген раслау бурычы Контроль органга йөкләнә.

6.20. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча Контроль орган җитәкчесе түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) шикаятьне канәгатьләндерми;

2) Контроль орган карарын тулысынча яисә өлешчә юкка чыгара;

3) Контроль орган карарын тулысынча юкка чыгара һәм яңа карар кабул итә;

4) Контроль органы вазыйфаи затларының гамәлләрен (гамәл кылмавын) законсыз дип таный һәм асылы буенча, шул исәптән билгеле бер гамәлләрне башкару турында, карар чыгара.

6.21. Кабул ителгән карарны нигезләүче контроль орган карары, аны үтәү срогы һәм тәртибе дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталында контрольдә торучы затның шәхси кабинетында һәм (яисә) региональ дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында кабул ителгән көннән алып бер эш көненнән дә соңга калмыйча урнаштырыла.

Контроль органның дәүләт яисә закон белән саклана торган башка серне тәшкил итүче белешмә һәм документларны үз эченә алган шикаятьне карау йомгаклары турындагы карары контрольдә торучы затка дәүләт яисә башка саклануучы сер турында Россия Федерациясе законнары таләпләрен үтәп, кәгазь чыганакта җибәрелә.

Расланган
Татарстан Республикасы Әлки
муниципаль районы Борис авыл
җирлеге Советының 2022 елның 4
февралендәге 36 номерлы карарына
3 нче кушымта

Борис авыл җирлегендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольнең төп күрсәткечләре һәм аларның максатчан әһәмияте, төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольнең индикатив күрсәткечләре

1. Борис авыл җирлегендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольнең төп күрсәткечләре һәм аларның максатчан әһәмияте:

| Төп күрсәткечләр | Максатчан төшенчәләр (%) |
|---|---|
| Мәҗбүри таләпләрне бозулар ачыкланган саннан мәҗбүри таләпләрне бозуның бетерелгән өлеше | 70-80 |
| Контроль орган гамәлләренә (гамәл кылмавына) һәм (яисә) аның вазыйфаи затларына кергән шикаятьләрнең гомуми санынннан контроль чаралар уздырганда нигезләнгән шикаятьләр өлеше | 0 |

2.Төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольнең индикатив күрсәткечләре:

1) хисап чорында уздырылган планлы контроль (күзәтчелек) чаралары саны;

2) хисап чорында уздырылган планнан тыш контроль (күзәтчелек) чаралары саны;

3) хисап чорында контроль объектының мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары белән расланган параметрларга туры килүен ачыклау нигезендә үткәрелгән тикшерүләр, яки хисап чорында контроль объектының мондый параметрлардан читләшүенә планнан тыш контроль (күзәтчелек) чаралары саны;

4) хисап чорында үзара хезмәттәшлек нәтиҗәсендә үткәрелгән контроль (күзәтчелек) чараларының гомуми саны;

5) хисап чорында үткәрелгән һәр КНМ төре буенча үзара хезмәттәшлек алып барылган контроль (күзәтчелек) чаралары саны;

6) хисап чорында дистанцион хезмәттәшлек чараларын кулланып үткәрелгән контроль (күзәтчелек) чаралары саны;

7) хисап чорында үткәрелгән мәҗбүри профилактик визитлар саны;

8) хисап чорында игълан ителгән мәҗбүри таләпләрне бозуга юл куймау турында кисәтүләр саны;

9) хисап чорында мәҗбүри таләпләрне бозулар ачыкланган контроль (күзәтчелек) чаралары саны;

10) хисап чорында административ хокук бозулар турында эшләр кузгатылган контроль (күзәтчелек) чаралары саны;

11) хисап чорында контроль (күзәтчелек) чаралары нәтиҗәләре буенча салынган административ штрафлар суммасы;

12) хисап чорында контроль (күзәтчелек) чараларын үткәрүне килештерү турында прокуратура органнарына җибәрелгән гаризалар саны;

13) хисап чорында прокуратура органнарына килештерүдән баш тарткан контроль (күзәтчелек) чараларын үткәрүне килештерү турында прокуратура органнарына җибәрелгән гаризалар саны;

14) хисап чоры ахырына контрольдә тотуның исәпкә алынган объектларының гомуми саны;

15) хисап чоры ахырына хәвеф-хәтәр категориясе буенча хәвеф-хәтәр категориясенә кертелгән контроль объектлары саны;

16) хисап чоры ахырына исәпкә алынган контрольдә торучы затлар саны;

17) хисап чорында исәпкә алынган контроль (күзәтчелек) чаралары уздырылган контрольдә торучы затлар саны;

18) хисап чорына контрольдә торучы затлар тарафыннан суд тәртибендә кадәр бирелгән шикаятьләрнең гомуми саны;

19) хисап чорында контроль (күзәтчелек) орган карау срогын бозган шикаятьләр саны;

20) хисап чорына контрольдә торучы затлар тарафыннан суд тәртибендә кадәр бирелгән, карау йомгаклары буенча контроль (күзәтчелек) органы карарын тулысынча яки өлешчә юкка чыгару турында яки контроль (күзәтчелек) органнары вазыйфаи затларының гамәлләрен (гамәл кылмауларын) гамәлгә яраксыз дип тану турында карар кабул ителгән шикаятьләр саны;

21) хисап чорында контрольдә торучы затлар тарафыннан суд тәртибендә җибәрелгән контроль (күзәтчелек) органнары карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмауларына) дәгъва белдерү турында дәгъвалар саны;

22) хисап чорында контрольдә торучы затлар тарафыннан суд тәртибендә җибәрелгән гаризада контроль (күзәтчелек) органнары карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмауларына) дәгъва белдерелгән таләпләрне канәгатьләндерү турында карар кабул ителгән дәгъвалар саны;

23) хисап чорында дәүләт контролен (күзәтчелеген) оештыру һәм гамәлгә ашыруга таләпләрне тупас рәвештә бозып үткәрелгән һәм аларның нәтиҗәләре дөрес түгел дип табылган һәм (яисә) юкка чыгарылган контроль (күзәтчелек) чаралары саны.